**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.10.2021 № 949

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2025 елларга Кама Тамагы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 апрелендәге 479 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасының 3 нче кушымтасына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 елның 25 сентябрендәге 916 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2025 елларга Кама Тамагы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 апрелендәге 479 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга Кама Тамагы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Программага 1 нче кушымтаның 35 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сатып алына торган торак бина (шул исәптән өлешләп төзү объекты булып торучы) яки торак йорт төзелеше  Татарстан Республикасы территориясендә алып барылырга тиеш.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең  төзелеш һәм ТКХ буенча  урынбасары А.М. Шәрәфиевка йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин